ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 424 «12» 12 2022 ел

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә хәрби хезмәт узу яисә ирекле ярдәм күрсәтү чорына муниципаль милектәге мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм штраф санкцияләрен кулланмыйча гына аренда килешүләрен өзү мөмкинлеге бирү чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 октябрендәге 3046-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә яисә ирекле ярдәм күрсәтү чорына Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору турында» 2022 елның 16 ноябрендәге 2507-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, арендага физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләр, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган юридик затлар (әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләр яки юридик затны гамәлгә куючы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация үткәрүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба - Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт узучы яки

000001150

Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булса) алган мөлкәт (шул исәптән җир кишәрлекләре) арендасы шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) бу боерыкның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп торуны (алга таба – аренда түләвен кичектереп тору);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеген.

2. Бу боерыкның 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен кичектереп тору чорында шартнамә буенча арендалана торган мөлкәт файдаланылмау;

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен яки Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзү хакында хәбәрнамә күчермәсен теркәп, арендага бирүчегә әлеге контрактлар төзелгән башкарма хакимиятнең федераль органнары тарафыннан бирелгән аренда түләвен кичектереп тору турында хәбәрнамә җибәрә;

бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән арендага алучыга бу боерыкның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләве кичектереп торыла;

аренда түләве буенча бурыч аренда түләвен кичектереп тору чоры тәмамланган көннән аренда шартнамәсенә теркәлгән өстәмә килешү нигезендә этаплап, айга иң күбе 1 тапкыр, тигез түләүләр белән түләнергә тиеш, аның күләме аренда шартнамәсе буенча ай саен түләнә торган аренда түләве күләменең яртысыннан артмаска тиеш;

аренда түләвен кичектереп торуга бәйле рәвештә, арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

бу боерыкның 4 пунктында күрсәтелгән чорда арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибе һәм сроклары үтәлмәүгә бәйле рәвештә, штрафлар, чит кеше акчасын файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

3. Бу боерыкның 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән, штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәсен өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация үткәрү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен яки Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзү хакында хәбәрнамә күчермәсен теркәп, арендага бирүчегә әлеге контрактлар төзелгән башкарма хакимиятнең федераль органнары тарафыннан бирелгән аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә җибәрә;

аренда шартнамәсе арендага бирүче тарафыннан аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә алынган көннән соң өзелергә тиеш;

аренда шартнамәсен өзүгә бәйле рәвештә, штрафлар, чит кеше акчасын файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

4. Аренда түләвен кичектереп тору срогы 90 көнгә арттырылган мобилизация срогы кебек исәпләп чыгарыла һәм бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән зат мобилизация чорында бурычларны башкарганда алган имгәнүне (җәрәхәт алу, травма, контузияне) яки авыруны дәвалау өчен стационар шартларда хастаханәләрдә, госпитальләрдә, башка медицина оешмаларында булган чорга, шулай ук бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән зат хәбәрсез югалган дип танылган очракта –шулай ук аны хәбәрсез югалган дип тану турында суд карары гамәлдән чыкканга кадәр яисә суд тарафыннан аны үлгән дип игълан иткәнгә кадәр озынайтыла.

Бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән зат һәлак (вафат) булган очракта, әгәр ул мобилизация чорында яисә әлеге чордан соң, әмма мобилизация чорында алынган имгәнү (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) яисә авыру аркасында үлгән (вафат) булса, шулай ук аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип таныган очракта, кичектереп тору чоры өчен аренда түләве алынмый.

Үлемгә яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип тануга китергән имгәнүнең (яралану, җәрәхәтләнү, контузиянең) мобилизация чоры белән сәбәпле бәйләнеше хәрби табиблар комиссияләре һәм (яки) медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарына, шулай ук алар карамагындагы дәүләт предприятиеләренә һәм дәүләт учреждениеләренә Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарына оператив идарә итү хокукында, дәүләт предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында яки оператив идарә итү хокукында яки дәүләт учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән, арендага физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләр, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган юридик затлар (әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләр яки юридик затны гамәлгә куючы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация үткәрүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт уза торган яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булса) алган дәүләт мөлкәте арендасы шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) бу боерыкның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп торуны;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеген.

6. Бу боерыкның 5 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору бу боерыкның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Бу боерыкның 5 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән, штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәсен өзү бу боерыкның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Бу боерыкның гамәле 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының https://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов